| | |
|---|---|
| БАВЛИНСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03.12.2019 Баулы шәһәре № 120

Төзелгән килешүләр нигезендә, "Баулы шәһәре" муниципаль берәмлеге бюджетыннан Баулы муниципаль районы бюджетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешүләр төзү тәртибе хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.3 статьясы нигезендә Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Төзелгән килешүләр нигезендә, "Баулы шәһәре" муниципаль берәмлеге бюджетыннан Баулы муниципаль районы бюджетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешүләр төзү тәртибен расларга (1нче кушымта).

2. Карар 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитетына йөкләргә.

Баулы шәһәре Мэры,
шәһәр Советы рәисе Р.Х. Гатиятуллин

1нче кушымта

Төзелгән килешүләр нигезендә, “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге бюджетыннан Баулы муниципаль районы бюджетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешүләр төзү тәртибе

1. Әлеге тәртип «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетыннан, төзелгән килешүләр нигезендә, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен Баулы муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешүләр төзүгә бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала (алга таба - килешү).

Килешүдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) субсидияләрнең  бюджетара трансфертларның максатчан билгеләнеше;

б) башка бюджетара трансфертларны күчерү һәм тоту шартлары;

в) башка бюджетара трансфертлар бирүгә каралган бюджет ассигнованиеләре күләме;

г) башка бюджетара трансфертларны күчерү графигы;

д) башка бюджетара трансфертларны бирү һәм тоту өчен билгеләнгән шартларның үтәлешен тикшереп тору тәртибе;

е) финанс тәэминаты чыганагы башка бюджетара трансфертлар булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе.

Килешүгә үзгәрешләр кертүне һәм аны өзүне күздә тоткан килешү, өстәмә килешүләр билгеләнгән формалар нигезендә төзелә.

Килешү проектын әзерләү «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла. «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Килешү проекты Баулы муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрелә. Килешү «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе һәм Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан имзалана.

Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты, башка бюджетара трансфертлар алу өчен, «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма

комитеты тарафыннан билгеләнгән вакытта түбәндәге документларны Баулы муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыра:

- "Баулы шәһәре" муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан расланган форма буенча башка бюджетара трансфертлар бирүгә гариза;

- акчаларга ихтыяҗны раслаучы документлар (шартнамәләр, контрактлар, башкарылган эшләр актлары).

2. Баулы муниципаль районы бюджетына «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар шушы тәртипкә кушымта нигезендә форма буенча килешүләр төзү шарты белән бирелә.

Башка бюджетара трансфертлар район бюджетына Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган территориаль органнары счетларына күчерелә.

Әлеге бюджетара трансфертларны килешү төзелгән вакытка кадәр бирү җыелма бюджет язмасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты кеременә күчерелергә тиеш.

Башка бюджетара трансфертларны биргән елдан соң килгән елның 1 гыйнварына файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар калдыгы Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләре нигезендә «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Максатчан файдалануны закон нигезендә «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты һәм Баулы муниципаль районының финанс-бюджет палатасы контрольдә тота.

2нче кушымта

Төзелгән килешүләр нигезендә, “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге бюджетыннан Баулы муниципаль районы бюджетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен башка бюджетара трансфертлар бирү турында _______ номерлы килешү

«__» ___________ 2019ел.

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге башкарма комитетының исемннән ____________________________ нигезендә эш итүче җитәкчесе ________________________ һәм гамәлдәге Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы җирлеге Башкарма комитеты исеменнән Нигезләмә нигезендә эш итүче җитәкчесе ___________________________________________________________ (алга таба "яклар" дип аталачак) «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетыннан Баулы муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе нигезендә, төзелгән килешүләр нигезендә, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен, түбәндәгеләр турында әлеге килешүне төзеделәр.

1.Килешү предметы

1.1. Әлеге килешүнең предметы – «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетыннан Баулы муниципаль районы бюджетына төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруга башка бюджетара трансфертлар (алга таба – башка бюджетара трансфертлар) бирү.

1.2. Баулы муниципаль районына башка бюджетара трансфертлар түбәндәге чараларга

бирелә:____________________________________________________________

_______________________________________________________________________

_______________________________________________________________________

(башка бюджетара трансфертлар бүлеп бирелә торган чаралар исемлеген күрсәтергә)

2. Башка бюджетара трансфертлар бирү һәм күчерү тәртибе һәм шартлары

2.1. Башка бюджетара трансфертлар _____ елга һәм 20___ һәм 20____ еллар план чорына “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге бюджеты турындагы карарда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.

2.2. 20___ елга һәм 20___ һәм 20____ еллар план чорына «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты хисабына Баулы муниципаль районы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертларның гомуми күләме_______________(__________________________) сум.

(сүзләр белән сумма)

2.3. Баулы муниципаль районы Башкарма комитена башка бюджетара трансфертлар күчерү Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль органының бюджетлар үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган счетына, Килешүгә кул куелганнан соң 10 эш көне эчендә җирле, башкарыла торган чыгымнарны раслаучы документлар (шартнамәләр, контрактлар) тапшырганда башкарыла.

## 3. Якларның үзара хезмәттәшлеге

3.1. “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге башкарма комитеты түбәндәге бурычларны үз өстенә ала:

3.1.1. Район башкарма комитеты тарафыннан әлеге килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары үтәлгәндә, район бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирүне тәэмин итәргә;

3.1.2. Башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын контрольдә тотарга;

3.1.3. Акчаларның максатчан тотылуын раслаучы документларны тикшерүне тормышка ашырырга;

3.1.4. Әлеге килешүнең 3.4.1. п. Нигезендә Башкарма комитет мөрәҗәгатен кабул иткән көннән алып 30 эш көне эчендә әлеге килешүнең үтәлешенә бәйле мәсьәләләр буенча район башкарма комитетына аңлатмаларны җибәрергә.

3.2. “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге башкарма комитеты хокуклы:

3.2.1. Фактта башкарылган эш (күрсәтелгән хезмәтләр, куелган товарлар) күләмнәрен, әлеге Килешү кысаларында бүлеп бирелгән акчаларны дөрес куллануны сайлап тикшерүне гамәлгә ашыру;

3.2.2. Башка бюджетара трансфертлар биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, районга башка бюджетара трансфертларны кире кайтаруны таләп итәргә.

3.3. Баулы муниципаль районы башкарма комитеты түбәндәге бурычларны үз өстенә ала:

3.3.1. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдалануны тәэмин итәргә;

3.3.2. Эшләрне _______________________ кадәр башкарырга.

(көне, ае, елы)

3.3.3. Төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен район бюджетына бирелгән башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап тапшырырга;

3.3.4. Соратып алу буенча башка бюджетара трансфертлар биргәндә билгеләнгән шартларның, максатларның һәм тәртипләрнең үтәлешен контрольдә тоту өчен кирәкле мәгълүмат һәм документлар тапшырырга;

3.4. Баулы муниципаль районы башкарма комитеты хокуклы:

3.4.1. Әлеге килешүнең үтәлешенә бәйле аңлатма алу өчен мөрәҗәгать итәргә.

4. Бюджетара трансфертлар бирү шартларын бозганда аны һәм башка бюджетара трансфертларның файдаланылмаган калдыгын кире кайтару тәртибе

4.1. Башка бюджетара трансфертларны бирү шартларын бозган очракта аны кире кайтару түбәндәге тәртиптә башкарыла.

Боерык чыгарылганнан соң биш эш көне эчендә районга бүлеп бирелгән бюджет акчаларын кире кайтару кирәклеге турында язма хәбәр җибәрелә. "Баулы шәһәре" муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының язмача хәбәрнамәсе алынганнан соң биш эш көне эчендә Район акчаларны кире кайтарырга тиеш.

Күрсәтелгән акчаларны билгеләнгән срокта ирекле кире кайтарудан баш тартканда, әлеге акчалар суд тәртибендә эзләтеп алыналар.

4.2. Хисап елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына кулланылмаган башка бюджетара трансфертларның калган өлешен кире кайтару түбәндәге тәртиптә башкарыла.

Башка бюджетара трансфертларның калганы район тарафыннан агымдагы финанс елының беренче ун эш көне дәвамында шәһәр муниципаль берәмлеге бюджеты кеременә кире кайтарыла.

Ихтыяҗы расланган башка бюджетара трансфертларның акчалары агымдагы финанс елында Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә район бюджетына шул ук максатларга кире кайтарылырга мөмкин.

## 5. Башка бюджетара трансфертларны максатчан куллануны контрольдә тоту тәртибе

5.1. «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылуын контрольдә тота.

## 6. Килешүнең гамәлдә булу срогы

6.1. Әлеге Килешү яклар тарафыннан имзаланган вакытта үз көченә керә һәм яклар әлеге килешү буенча йөкләмәләрне тулысынча үтәүгә кадәр гамәлдә була.

## 7. Якларның җаваплылыгы

7.1. Район башкарма комитеты бирелгән башка бюджетара трансфертларны максатчан файдалану өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

## 8. Башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап бирү тәртибе

8.1. Баулы муниципаль районы башкарма комитеты Әлеге Килешүнең 3.3.3 пункты нигезендә хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр кәгазьдә һәм электрон чыганакларда хисап бирә. Проектны гамәлгә ашыру срогы Килешү төзү елыннан соң килгән елда тәмамланса - проектны гамәлгә ашыру тәмамланганнан соң 1 айдан да артмаган вакыт эчендә.

## 9. Йомгаклау нигезләмәләре

9.1. Әлеге килешүне үзгәртү яклар инициативасы буенча гамәлгә ашырыла һәм әлеге килешүгә Өстәмә килешү рәвешендә рәсмиләштерелә, ул аның аерылгысыз өлеше булып тора.

9.2. Әлеге Килешүдә каралмаган барлык мәсьәләләрдә яклар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына таяна.

9.3. Әлеге Килешү ике нөсхәдә төзелгән, бер нөсхә Совет өчен, икенчесе - җирлек өчен.

## 10. Юридик адреслар

| | |
|---|---|
| Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты:______________________________<br>__________________________________________ | Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты:<br>______________________________________<br>______________________________________ |

## 11. Яклар имзалары

| | |
|---|---|
| Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты: | Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты: |
| ________________/ ____________<br>М.У. (Ф.И.О.) | ________________/ ____________<br>М.У. (Ф.И.О.) |
| «__»_________ 20___ел. | «__»__________20 ___ел. |

_____номерлы ____________ Китешү нигезендә
финанслау чыганагы бюджетара трансфертлар булган
чыгымнар турында хисап
20____ елның «___»__________

Алучы атамасы: ________________________________

Үл. берәмлеге: сум (төгәллеге унлыкка кадәр)

| Күрсәткеч атамасы | Сумма |
|---|---|
| Ел башына калдык, барлыгы | |
| шул исәптән:<br>ихтыяҗы расланган | |
| Муниципаль район бюджетына кире кайтарылырга тиешле | |
| Барлыгы акча керде | |
| Чыгымнар буенча түләүләр, барлыгы | |
| шул исәптән муниципаль район бюджетыннан да | |
| Муниципаль район бюджетына кайтарылды, барлыгы: | |
| шул исәптән: максатчан билгеләнеш буенча сарыф ителмәгәннәре | |
| Хисап чоры ахырына файдаланылмаган акчалар, барлыгы: | |
| шул исәптән: шул ук максатларга юнәлдерү таләп ителә | |
| Кире кайтарылырга тиеш | |

Башкаручы: __________________ ____________________ ____________________
(вазыйфа) имза (имза расшифровкасы)

Баулы муниципаль районы
Финанс-бюджет палатасы
җитәкчесе ______________ ____________________
имза имза расшифровкасы

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе______________ ____________________
имза имза расшифровкасы